Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге Советы

КАРАР

«7 » сентябрь 2020 ел № 129

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 сентябрендәге 89 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советы, КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 сентябрендәге 89 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктта. «(2 нче кушымта)», «(3 нче кушымта)» сүзләрен «үзара салым үрнәгендә 2 нче кушымта мисалында», «үзара салым үрнәгендә 3 нче кушымта мисалында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.9.2 пунктында. «(5,6 нчы кушымта)» сүзләрен «(№5,6 нчы кушымта мисалын үзара салым үрнәгендә)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.3 пунктта нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Торак пунктта яшәүченең сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлек ачыкланган очракта, гражданның шәхесен раслаучы документлар булган очракта, җыенда катнашу рөхсәт ителә.»;

1.4. 3.17 пунктта җәяләр эчендәге “(14 нче беркетмә)” сүзен җәяләр эчендәге “(14 нче кушымта)”сүзенә алмаштырырга;

1.5. 3.18 пунктында түбәндәге «җирлек башлыгы имзалаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль норматив хокукый актлар булып торалар, муниципаль берәмлек башлыгы яисә җыенда рәислек итүче бүтән зат тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш»;

1.7. 4.5 пунктта түбәндәге сүзләрне «(№15 кушымта мисалында үзара салым үрнәгендә)»;

1.8. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 7 нче кушымта белән тулыландырырга:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турындагы Нигезләмәгә 7 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү
БЮЛЛЕТЕНЕ

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган мәсьәләнең эчтәлеге | «Әйе» | ☐ |
| | «Юк» | ☐ |
| | | |

1.9. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 15 нче кушымта белән тулыландырырга:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советының «__»______ 20___ ел № ____
карарына 15 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге
_________ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

__________ 20__ №___

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «__» ______ 20___ елда, 00 сәгать 00 минутта «__» ______ 20__ елда ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

« РИЗА» «КАРШЫ»

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында ______катнашучы кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны ____, бу ___% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» диеп гражданнар җыенында катнашучыларның ____ тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучыларның ____ тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең _________ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең ________ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган яшәүчесеннән _____________ елда _____ сум күләмендә үзара салым акчаларын җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

______________________________________________________________

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче _____________ /_____________/

______________________________________________________________________________

1.10. Нигезләмәнең 7,8,9,10,11,12,13 нче кушымталарын № 8,9,10,11,12,13,14 нче кушымталары диеп санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга, http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлге Советы рәисе Н.В. Авдеева